**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы**
**Савруш авыл җирлеге башкарма комитеты**

# КАРАР

№ 2 01.02.2016 ел

**2016 елга Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлегендә наркотикларга каршы чаралар планын раслау турында**

«2020 елга кадәр Россия Федерациясенең наркотикларга каршы дәүләт сәясәте стратегиясен раслау турында» 09.06.2010 ел, № 690 Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә, наркомания таралу куркынычын киметү максатларында, "наркотик чараларның, психотроп матдәләрнең законсыз әйләнешенә каршы тору буенча өстәмә чаралар турында" Россия Федерациясе Президентының 18.10.2007 ел, № 1374 Указына таянып, Савруш авыл җирлеге комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2016 елга Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Савруш авыл җирлеге территориясендә наркотикларга каршы чаралар планын расларга (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында игълан итәргә: http:// aksubayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам

Аксубай муниципаль районы
Савруш авыл җирлеге
Җитәкчесе: А.Г.Кузьмин.

Кушымта №1
Савруш авыл җирлеге
башкарма комитеты карарына
№ 2    01.02.2016 ел

**Савруш авыл җирлеге 2015 елга наркотикларга каршы чаралар ПЛАНы**

| № п/п | чара | Башкару вакыты | башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1. Наркотикларны законсыз куллануны һәм наркоманияне профилактикалау | | | |
| 1.1 | Наркотикларны законсыз кулланунын хокукый һәм медицина аспектларын яктырту максатында хокук саклау органнары һәм сәламәтлек саклау органнары хезмәткәрләренең мәктәп укучылары, авыл яшьләре белән даими очрашуларын үткәрү. | Ел дәвамында | Мәктәп директорлары, Аксубай районы эчке эшләр бүлеге УПУП (килештерү буенча) |
| 1.2 | Яшьләр акцияләрен үткәрү:<br>»Наркотикларсыз дөнья " акциясе<br>Бөтендөнья сәламәтлек көненә багышланган Акция<br>"СПИД йокламый»акциясе-протест | <br>апрель<br>апрель<br>декабрь | Авыл мәдәният йорты директорлары, Китапханә мөдирләре, ФАП мөдирләре (килешү буенча) |
| 1.3 | Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән спорт ярышлары, турнирлар уздыру | Ел дәвамында | Мәктәп директорлары, мәдәният йорты (килешү буенча) |
| 2. Наркотикларның законсыз әйләнешен кисәтү чаралары | | | |
| 2.1 | Наркотиклы үсемлекләрнең законсыз чәчүлекләрен ачыклау буенча оператив-тикшерү чаралары үткәрү, наркотиклар әзерләүчеләрне, ташучыларны транспортлау маршрутларында тоткарлау | май-октябрь | Аксубай районы эчке эшләр идарәсе (килешү буенча) |
| 2.2 | Авыл җирлеге территориясендә кыргый киндер үстерү планы-схемасын төзү | 2 квартал | Авыл җирлеге башкарма комитеты, Аксубай районы ЭЭМ УУП (килешү буенча) |
| 2.3 | Савруш авыл җирлеге территориясендә кыргый киндер һәм законсыз чәчүлекләрне ачыклау һәм юк итү буенча чаралар үткәрү | июнь - октябрь | Авыл җирлеге башкарма комитеты, Аксубай районы ЭЭМ УУП (килешү буенча) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2.4 | Наркотик чаралар кулланучы затлар турында санлы исәп мәгълүматларын системалы рәвештә чагыштыру | Ел дәвамында | Аксубай районы эчке эшләр бүлеге ӨУП, ФАП мөдирләре (килешү буенча) |
| 2.5 | Наркотик матдәләр булган үсемлекләрне законсыз үстергән өчен административ һәм җинаять җаваплылыгын аңлату, шулай ук җәмәгатьчелекнең наркотиклар куллануга тискәре мөнәсәбәтен формалаштыру максатында авыл җирлеге торак пунктларында яшәүчеләр җыелышларын үткәрү | Ел дәвамында | РФ ЭЭМ УУП (килештерү буенча), Савруш авыл җирлеге Советы |